ГЛАВА КОРГУЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная площадь, д.1, с. Коргуза,
422586

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАРАГУЖА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 1 нче йорт, Карагужа авылы,
422586

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

03.12.2025　　　　　　　　　　　　01

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48

с. Коргуза

## Үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

“Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 13 декабренә Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Патрикеево авылында гражданнардан үзара салым җыюны кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегенең Патрикеево авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- Патрикеево торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

«ӘЙЕ»　　　　　　　　«ЮК»

3. Патрикеево авылы клубы бинасында түбәндәге адрес буенча халык җыенын уздырырга: Патрикеево авылы, Береговая урамы, 10 йорт 13.00 сәгатьтә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Карагуҗа авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　Д.В.Плохов